КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 16 март г.Казань № 213

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 1 декабрь, 1024 нче карары белән расланган 2026 – 2035 елларга Татарстан Республикасының өлкән яшьтәге гражданнар һәм инвалидлар өчен социаль хезмәт күрсәтү стационар оешмаларының кадрлар белән тәэмин ителешен ныгыту чаралары планына («юл картасына») үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2026 – 2035 елларга Татарстан Республикасының өлкән яшьтәге гражданнар һәм инвалидлар өчен социаль хезмәт күрсәтү стационар оешмаларының кадрлар белән тәэмин ителешен ныгыту чаралары планын («юл картасын») раслау турында» 2025 ел, 1 декабрь, 1024 нче карары белән расланган 2026 – 2035 елларга Татарстан Республикасының өлкән яшьтәге гражданнар һәм инвалидлар өчен социаль хезмәт күрсәтү стационар оешмаларының кадрлар белән тәэмин ителешен ныгыту чаралары планына («юл картасына»), файдаланылган кыскартылмалар исемлегенең алтынчы абзацындагы «психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән интернат йортлар, психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат йортлары» сүзләрен «социаль хезмәт күрсәтү йортлары, социаль хезмәт күрсәтү буенча балалар йортлары» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин